ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» декабрь 2025 ел №1215

**“2026 - 2030 елларга Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” муниципаль программасын раслау турында**

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясен, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте Концепциясе турында” 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасын раслау турында” 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карарын үтәү йөзеннән Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “2026 - 2030 елларга Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” муниципаль программасын (алга таба - Программа) расларга.
2. Арча муниципаль районы башкарма комитетын Программаның муниципаль заказчысы – координаторы итеп билгеләргә.
3. “Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы” муниөипаль казна учреждениесена Программа чараларын финанслауны тәэмин итәргә.
4. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “2021-2025 елларга Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” муниципаль программасын раслау турында” 2020 елның 08 декабрендәге 984 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштырып халыкка җиткерергә

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ә.Галимуллин

**РАСЛАНДЫ**
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
“11” декабрь 2025 ел,
№1215 карары белән

**“2026 - 2030 елларга Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” муниципаль программасы**

Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2026 - 2030 елларга Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666нчы номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте Стратегиясе.<br>Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган “2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасының башка телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү” дәүләт программасы.<br>Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте Концепциясе турында” 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 Указы.<br>“Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасын раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары (2025 елның 03 ноябренә үзгәрешләрне кертеп) |
| Программаны төп эшләүче | Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе |
| Программаның төп чараларын башкаручылар (килешү буенча) | Арча муниципаль районы башкарма комитеты, “Мәдәният идарәсе”, “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениеләре, мәдәният учреждениеләре, мәгариф оешмалары, өстәмә белем бирү учреждениеләре, авыл җирлекләре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлегенең миграция мәсьәләләре бүлеге, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, |

| | |
|---|---|
| | “Арча хәбәрләре” газетасы редакциясе, “Арча” телерадиокомпаниясе (алга таба – “Арча” ТРК) |
| Программаның максаты | Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклау, гомумроссия гражданлык үзенчәлеген (Россия милләтен) ныгыту, мигрантларның уңышлы социаль һәм мәдәни адаптациясе һәм интеграциясе |
| Программаның бурычлары | 1. Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни үсешенә ярдәм итү һәм гомумроссия гражданлык үзенчәлеген ныгыту;<br>2. Арча муниципаль районы территориясендә дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль органнарның граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү;<br>3. Мигрантларның этникара һәм конфессияара тынычлыгы һәм татулыгына, социомәдәни адаптациясенә һәм интеграциясенә шартлар тудыру һәм ярдәм итү;<br>4. Республика һәм районнан читтә татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу һәм үстерү өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтү;<br>5. Арча муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру;<br>6. Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-белем бирү һәм мәгълүмати тәэмин итү;<br>7. Программа куйган бурычларны үтәү кысаларында республика, бөтенроссия, халыкара бәйгеләрдә һәм фестивальләрдә катнашу. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2026 - 2030 еллар |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Программаны финанслау Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетының агымдагы акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла<br>2026 елда – 300 мең сум.<br>2027 елда – 300 мең сум.<br>2028 елда – 300 мең сум.<br>2029 елда – 300 мең сум.<br>2030 елда – 300 мең сум. |

| | |
|---|---|
| | Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразланган характерда була һәм район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтелергә тиеш |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаның индикаторлары:<br>1. Районда этникара мөнәсәбәтләрнең торышын уңай бәяләүче Арча муниципаль районында яшәүчеләрнең өлешен арттыру (репрезентатив сораштыру нәтиҗәләре буенча билгеләнә):<br>2026 елда – 75 процент;<br>2027 елда – 75,5 процент;<br>2028 елда – 76 процент;<br>2029 елда – 76,5 процент;<br>2030 елда – 77 процент.<br>2. Районда конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышын уңай бәяләүче Арча муниципаль районында яшәүчеләрнең өлешен арттыру (репрезентатив сораштыру нәтиҗәләре буенча билгеләнә):<br>2026 елда – 72 процент;<br>2027 елда – 73 процент;<br>2028 елда – 74 процент;<br>2029 елда – 75 процент;<br>2030 елда – 76 процент.<br>3. Үзләренең этномәдәни ихтыяҗларын тормышка ашырудан канәгать булган Арча муниципаль районында яшәүчеләрнең өлешен арттыру (репрезентатив сораштыру нәтиҗәләре буенча билгеләнә):<br>2026 елда – 72 процент;<br>2027 елда – 73 процент;<br>2028 елда – 74 процент;<br>2029 елда – 75 процент;<br>2030 елда – 76 процент. |

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, шул исәптән ул хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар

“2026 - 2030 елларга Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” муниципаль программасы “Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте Концепциясе турында” Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә

ашыру” дәүләт программасы (2025 елның 03 ноябренә үзгәрешләр кертеп) нигезендә эшләнде.

Программа дәүләт хакимиятенең территориаль органнары, Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары, Арча муниципаль районы башкарма комитеты бүлекләре, мәдәният учреждениеләре, мәгариф учреждениеләре һәм иҗтимагый оешмалар тәкъдимнәрен исәпкә алып эшләнде.

Татарстан Республикасының дәүләт милли сәясәте Концепциясе нигезендә, дәүләт милли сәясәте объекты булып милләтара мөнәсәбәтләр һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең этномәдәни үсеше өлкәсе тора.

Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәте Концепциясе принципларына таянып, Программа Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруның максатларын, принципларын, төп юнәлешләрен, бурычларын һәм механизмнарын билгели, районда яшәүче халыкларның этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен оптималь шартлар тудыра. Татарстан Республикасының Арча муниципаль районында яшәүче халыклар вәкилләренең тарихи традицияләрен, табигый-климат һәм табигый-икътисадый шартларны, аларның тормышының социаль-мәдәни үзенчәлекләрен, геосәяси һәм милли чолганышларын, күршеләре белән үзара мөнәсәбәтләр тәҗрибәсен аңлауга таяна.

Тарихи яктан шулай килеп чыкты: уңай милләтара (этникара) һәм конфессияара хезмәттәшлекне тәэмин итүдә гадәттәгечә Татарстан Республикасының Арча муниципаль районында яшәүче барлык башка халыклар вәкилләренә караганда күпчелекне тәшкил итүче татар һәм рус халыклары вәкилләре төп роль уйный.

Арча муниципаль районында 2025 елның I кварталына халык саны 51031 кеше тәшкил иткән, шулардан татарлар – 46472 (91,1%), руслар – 3394 (8,14%). Идел буе халыклары вәкилләреннән район территориясендә чуашлар, удмуртлар, мордвалар, марилар яши, алар барлыгы 1165 (0,76%) кеше тәшкил итә.

Арча муниципаль районында, бөтен республикадагы кебек үк, халыкның милли составы динамик рәвештә үзгәрә – шәһәр һәм авыл җирлекләрендә элеккеге союздаш республикалардан чыккан яңа этник төркемнәр барлыкка килә (азәрбайҗаннар, әрмәннәр, үзбәкләр, таҗиклар, казакълар, кыргызлар, грузиннар, молдаваннар, төрекмәннәр).

2025 елның 10 аенда Арча районында вакытлыча яшәүче 2727 граждан һәм гражданлыгы булмаган зат миграция исәбенә куелган, шуларның 816сы беренче тапкыр. Вид на жительство буенча Арча районында 365 чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган затлар яши. Вакытлыча яшәүгә рөхсәт буенча 82 чит ил гражданы һәм гражданлыгы булмаган затлар яши. Агымдагы елда 21 кеше РФ гражданлыгын алган. Алдагы еллардагы кебек үк, чит ил гражданнары этник диаспораларга берләшмәгән, таркау яшиләр; мәдәни үзәкләр, иҗтимагый яки дини берләшмәләр төземәгәннәр.

Прокуратура, Эчке эшләр бүлеге һәм миграция хезмәте бүлеге мәгълүматы буенча, районда чит ил гражданнары булу белән бәйле оператив вәзгыять тотрыклы һәм криминоген вәзгыятькә йогынты ясамый. Хисап чорында Арча районында чит ил гражданнары тарафыннан җинаятьләр кылынмаган. Шуңа да карамастан, чит ил

гражданнарының легаль булмаган миграциясенә һәм законсыз эшчәнлегенә каршы тору максатында контроль-күзәтчелек чаралары уздырыла. 2025 елның 10 аенда 76 тикшерү чарасы уздырылган. Миграция өлкәсендәге законнарны бозган өчен (РФ КоАП 18.8-18.20 маддәләре) 45 административ беркетмә төзелгән.

Арча муниципаль районында дини оешмаларның гомуми саны конфессияләр киселешендә (саны; өлеше %ларда): ислам - 96 (98%), православие - 3 (2%), башка конфессияләр юк. Арча шәһәренең үзәк мәчетендә район имамнары җыелышлары район хакимияте, прокуратура һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге хезмәткәрләре катнашында уза. Җыелышларда райондагы этноконфессиональ хәлгә җентекле анализ ясала, мәчетләрнең проблемалы мәсьәләләре карала. Арча муниципаль районында дини һәм милләтара вәзгыять тотрыклы, конфликтлы хәлләр һәм проблемалар килеп чыкмады.

Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре планлы тәртиптә районның Иҗтимагый Советы, Арча район Советы, даими комиссияләр утырышларында, прокуратура органнары, хокук саклау органнары, Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча Эчке эшләр министрлыгының миграция мәсьәләләре бүлеге, ЗАГС бүлеге, массакүләм мәгълүмат чаралары, дини оешмалар вәкилләре катнашында эшлекле киңәшмәләрдә карала. Районның авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары полиция участок хезмәткәрләре белән бергәләп авыл җирлекләре территориясенә килгән чит ил гражданнарын, аларның теркәлү адреслары буенча фактик яшәүләрен контрольдә тотуны тәэмин итү буенча эш алып баралар, буш һәм хуҗасыз йортларны, биналарны, шулай ук социаль-мәдәни өлкә объектларын тикшерәләр; килгән һәм киткән чит ил гражданнары буенча Россия Федераль миграция хезмәтенең Арча районы буенча идарәсе белән даими рәвештә чагыштыру үткәрелә.

2025 елда террорчылыкка һәм экстремизмга каршы торуның оператив торышын анализлау шуны күрсәтә: җирле үзидарә органнары һәм Арча муниципаль районы хокук саклау органнары тарафыннан күрелгән профилактик, оператив һәм оештыру чаралары оператив торышны тотрыкландыру тенденциясен саклап калырга һәм район территориясендә террорчылык һәм экстремизм характерындагы җинаятьләргә юл куймаска мөмкинлек бирде. Район территориясендәге иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисадый һәм криминоген хәлне тотрыклы дип бәяләргә була. Массакүләм протест чыгышлары булмады, конфликтлы хәлләр һәм проблемалар килеп чыкмады.

Арча районы мәдәният йорты базасында “Татарстан Республикасы рус милли-мәдәни берләшмәсе” төбәк иҗтимагый оешмасының Арча бүлеге, “Татарстан халыклары Ассамблеясе” филиалы эшли. Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруда мәдәният учреждениеләре каршында эшләүче иҗат коллективлары актив катнаша: “Чордашлар” татар халык фольклор ансамбле, “Лейся, песня” рус вокаль-фольклор коллективы, “Русская песня” рус вокаль-фольклор коллективы, “Шишор” мари фольклор ансамбле, “Яшь йөрәкләр” татар вокаль ансамбле, керәшен фольклор коллективы һәм башкалар. Коллективларның иҗаты иң беренче чиратта туган телне пропагандалауга, милли гореф-гадәтләрне һәм йолаларны торгызуга, район территориясендә яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсешенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте Концепциясе турында” 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указы нигезендә хәзерге этапта әлеге өлкәдә өстенлекле мәсьәләләр билгеләнде.

Әлеге Программа Татарстан Республикасының Арча муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең уңай характерын саклап калуга юнәлдерелгән.

Программа планына үзара хөрмәт итү һәм күршелекнең күп гасырлык традицияләре нигезендә гражданнарның этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә ярдәм итә торган оештыру, мәдәни-массакүләм һәм мәгариф чаралары кертелгән.

## II. Программаны гамәлгә ашыруның төп максатлары, бурычлары, сроклары һәм этаплары

Программаның максаты һәм бурычлары Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006нчы номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасында (2025 елның 03 ноябренә үзгәрешләр кертеп), Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте өлкәсенә кагылышлы федераль һәм региональ законнар һәм норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

Программаның Максаты:

Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең цивилизацияле үсеше, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклау, гомумроссия гражданлык үзенчәлеген (Россия милләтен) ныгыту, мигрантларның уңышлы социаль һәм мәдәни адаптациясе һәм интеграциясе.

Программаның бурычлары:

1. Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни үсешенә ярдәм итү һәм гомумроссия гражданлык үзенчәлеген ныгыту;

2. Татарстан Республикасында һәм турыдан-туры Арча муниципаль районы территориясендә дәүләт һәм муниципаль органнарның дәүләт милли сәясәте өлкәсендә граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү;

3. Мигрантларның этникара һәм конфессияара тынычлыгы һәм татулыгына, социомәдәни адаптациясенә һәм интеграциясенә шартлар тудыру һәм ярдәм итү;

4. Республика һәм районнан читтә татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу һәм үстерү өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтү;

5. Арча муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру;

6. Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-мәгариф һәм мәгълүмати тәэмин итү.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2026-2030 еллар. Гамәлгә ашыру этаплары аерылмый. Программаның максатлары, бурычлары, чаралары буенча нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары турындагы мәгълүматлар аның кушымтасында китерелә.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты хисабына финанслана.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышында заказчы-координатор Арча муниципаль районы Башкарма комитеты йөзендә төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, чараларны гамәлгә ашыруның барышын һәм башкаручыларның акчалардан нәтиҗәле файдалануын тикшереп тора. Программа чаралары Программаның муниципаль заказчысы тарафыннан Программа чараларының барлык башкаручылары белән гамәлгә ашырыла торган муниципаль контрактлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы муниципаль учреждениеләр һәм оешмалар Татарстан Республикасы башкарма комитетына аның үтәлеше турында квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр мәгълүмат тапшыралар.

## V. программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген тасвирлау

Этномәдәни өлкәдә төп нәтиҗәләр, кагыйдә буларак, вакыт буенча кичектерелгән социаль эффектта, аерым алганда, төрле халык вәкилләренең мәдәниятенә, теленә һәм гореф-гадәтләренә карата толерантлык һәм ихтирамның үсүендә, кешеләрнең үз-үзләрен тоту нормаларының уңай үзгәрүендә, ТР Арча муниципаль районының тотрыклы үсешендә мөһим фактор буларак бердәм этномәдәни киңлекнең үсешендә чагыла.

Программаны гамәлгә ашырудан социаль-икътисадый файда социаль тотрыклылыкны, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны, этномәдәни үзенчәлекне саклаудан һәм Арча районында яшәүче халыкларның социаль-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән гыйбарәт һәм түбәндәгеләрдә чагыла:

этномәдәни һәм социаль хәлен яхшыртуда;

региональ һәм гомумроссия гражданлык үзенчәлеген ныгытуда;

этномәдәни потенциалны файдалануның нәтиҗәлелеген арттыруда;

милләтара конфликтларны булдырмауда.

Программаны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасының Арча муниципаль районында яшәүче халыклар вәкилләренең уңай милләтара (этникара) һәм конфессияара хезмәттәшлеген, этник һәм конфессиональ нигездә конфликтларны

кисәтүне һәм булдырмауны, мигрантларга җайлашу өчен шартлар тудыруны тәэмин итәчәк.

**“2026 - 2030 елларга Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру” муниципаль программасы чаралары планы**

| Чараларның исеме | Башкаручылар | Гамәлгә ашыру вакыты | Финанслау чыганагы, мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| **1. Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең милли-мәдәни үсешенә ярдәм итү һәм гомумроссия гражданлык үзенчәлеген ныгыту** | | | | | | | |
| 1.1. Традицион халык бәйрәмнәрен һәм йолаларын үткәрү: “Нәүрүз”, “Сабантуй”, “Май чабу”, “Раштуа”, массакүләм халык күңел ачулары: “Каз өмәсе”, “Аулак өйдә”, “Карга боткасы”, “Сөмбелә”, “Авыл көннәре”, урам бәйрәмнәре һ. б. | Башкарма комитетның «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе, «Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре» муниципаль бюджет учреждениесе, Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, район авыл җирлекләре | 2026 - 2030 еллар | район бюджеты 35,0 | район бюджеты 35,0 | район бюджеты 35,0 | район бюджеты 35,0 | район бюджеты 35,0 |
| 1.2. Календарь бәйрәмнәренә багышланган чаралар үткәрү (Ватанны саклаучылар көне, Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, Балаларны яклау көне, Россия көне, һәлак булганнар декадасы, инвалидлар декадасы, Ватан Геройлары көне, Халыклар бердәмлеге көне һ. б.) | Башкарма комитетның «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе, «Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре» муниципаль бюджет учреждениесе, авыл | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 30,0 | район бюджеты 30,0 | район бюджеты 30,0 | район бюджеты 30,0 | район бюджеты 30,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | җирлекләре, ТРК «Арча», «Арча хәбәрләре» газетасы редакциясе | | | | | | |
| 1.3. Арча муниципаль районы территориясендә гражданлык бердәмлеген нygыту темаларын чагылдырган агитбригадалар, театральләштерелгән тамашалар, рус һәм татар телләрендә тематик программалар һәм күңел ачу программалары, милли көрәш буенча турнирлар | Башкарма комитетның «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе, «Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре» муниципаль бюджет учреждениесе, Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, район авыл җирлекләре | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 |
| 1.4. Район смотрлары, бәйгеләр, фестивальләр оештыру:<br>- туган телләр фестивале;<br>- милли мәдәниятләр фестивале;<br>- театр коллективлары фестивале;<br>- фольклор коллективлары фестивале;<br>- эшче яшьләр иҗаты фестивале;<br>- район балалар фестивале;<br>- балалар иҗаты фестивальләре һәм бәйгеләры;<br>- “Арча йолдызлары” эстрада сәнгате фестивале;<br>- “Минем Ватаным Россия, минем йортым Татарстан” рәсем бәйгесе;<br>- район балалар өчен “Моңлы сазым” нәфис сүз бәйгесе;<br>- район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре һәм авыл җирлекләре көннәре кысаларында иҗади концерт программалары, КВН уеннары, урам бәйрәмнәре, спартакиадалар; | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе, «Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре» муниципаль бюджет учреждениесе, «Арча балалар сәнгать йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, район авыл җирлекләре, ТРК «Арча», «Арча хәбәрләре» газетасы редакциясе | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 40,0 | район бюджеты 40,0 | район бюджеты 40,0 | район бюджеты 40,0 | район бюджеты 40,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| - Милләтләр кроссы, спартакиадалар, җәяүле походлар һ. б. | | | | | | | |
| 1.5. “Безнең уртак йортыбыз – Татарстан” яшүсмерләр өчен хокукый мәктәп чаралары циклы:<br>- милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә экстремизмны һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча лекцияләр;<br>- тематик программалар;<br>- паспортлар тапшыру буенча тантаналы чаралар. | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, башкарма комитетның гражданлык хәлләрен теркәү бүлеге, ТРК «Арча», «Арча хәбәрләре» газетасы редакциясе | 2026 - 2030 еллар | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 |
| 1.6. Районның мәдәният учреждениеләрендә һәм мәгариф оешмаларында халыкара толерантлык көненә багышланган чаралар циклы | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе Башкарма комитетның «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 |
| 1.7. Тематик очрашулар һәм лекцияләр “Экстремизмга-юк!” хокук саклау органнары белгечләрен һәм хезмәткәрләрен җәлеп итеп | «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе, «Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре» муниципаль бюджет учреждениесе, белем бирү учреждениеләре, район авыл җирлекләре | 2026 – 2030 еллар | - | - | - | - | - |
| 1.8. Республика бәйгеләренең, фестивальләренең һәм форумнарының зона турларын уздыруны оештыру:<br>- “Йортыбыз Татарстан” этномәдәни фестивале;<br>- “Күптавышлы Татарстан»” музыка коралларында уйнау бәйгесе;<br>- “Балкыш” ветераннары арасында үзешчән иҗат фестивале; | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе, «Арча балалар | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 55,0 | район бюджеты 55,0 | район бюджеты 55,0 | район бюджеты 55,0 | район бюджеты 55,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| - “Созвездие–Йолдызлык” телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале;<br>- “Арча ягы, данлы Тукай ягы” балалар иҗаты бәйгесе;<br>- “Татар кызы” республика матурлык, талант һәм милли традицияләр бәйгесе һ. б. | сәнгать йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, ТРК «Арча», «Арча хәбәрләре» газетасы редакциясе | | | | | | |
| 1.9. Татарстан Республикасы көненә багышланган чараларны оештыру һәм үткәрү | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, авыл җирлекләре, ТРК «Арча», газета «Арча хәбәрләре» | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 30,0 | район бюджеты 30,0 | район бюджеты 30,0 | район бюджеты 30,0 | район бюджеты 30,0 |
| 1.10. Никахлашу тантаналарын үткәрү | Башкарма комитетның гражданлык хәлләрен теркәү бүлеге | 2026 – 2030 еллар | - | - | - | - | - |
| **2. Татарстан Республикасында һәм турыдан-туры Арча муниципаль районы территориясендә дәүләт һәм муниципаль органнарның дәүләт милли сәясәте өлкәсендә граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү** | | | | | | | |
| 2.1. Милли-мәдәни автономияләр җитәкчеләренең - Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте Концепциясен гамәлгә ашыруда НКА катнашуы мәсьәләсе буенча республика киңәшмәсендә катнашу | Арча муниципаль районы башкарма комитеты | 2026 – 2030 еллар | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты |
| 2.2. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча авыл җирлекләре башлыклары, башкарма комитет, социаль яклау, хокук саклау органнары, мәдәният учреждениеләре бүлекләре җитәкчеләре белән район семинар-киңәшмәләре үткәрү | Арча район Советы, башкарма комитет, авыл җирлекләре, «Арча хәбәрләре» район газетасы редакциясе | 2026 - 2030 еллар | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3. Дини оешмалар, иҗтимагый һәм милли берләшмәләр эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү | Арча муниципаль районы башкарма комитеты | 2026 – 2030 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.4. Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәмне оештыру | Арча муниципаль районы башкарма комитеты | 2026 - 2030 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.5. Районда милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышына мониторинг үткәрү | Арча район Советы, башкарма комитет, район авыл җирлекләре | 2026 - 2030 еллар | - | - | - | - | - |
| 2.6. Хезмәт мигрантлары өчен Россия, Татарстан тарихын һәм РФ, ТР законнары нигезләрен ачучы китап күргәзмәләре оештыру | «Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026 – 2030 еллар | - | - | - | - | - |
| **3. Мигрантларның милләтара һәм конфессияара тынычлыгын һәм татулыгын, социаль-мәдәни адаптациясен һәм интеграциясен тәэмин итү һәм аларга ярдәм итү** | | | | | | | |
| 3.1. Миграция процессларын өйрәнү, качаклар, мәҗбүри күченүчеләр проблемаларын хәл итү | Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча Эчке эшләр бүлегенең миграция мәсьәләләре буенча бүлеге | 2026 - 2030 еллар | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | бюджет Респуб-лики Татарстан | бюджет Респуб-лики Татарстан | бюджет Респуб-лики Татарстан |
| **4. Республика һәм районнан читтә татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу һәм үстерү өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтү** | | | | | | | |
| 4.1. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты аша татарларның милли-мәдәни автономияләре белән хезмәттәшлек итү юлы белән РФ төбәкләре белән элемтәләрне киңәйтү:<br>- Россия Федерациясенең төрле төбәкләрендә – татарлар яши торган урыннарда Сабантуй милли бәйрәмнәрендә катнашу; | Арча район Советы, башкарма комитет,<br>Башкарма комитетның «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе | 2026 - 2030 еллар | бюджет Респуб-лики Татарстан | Татарстан Республикасы бюджеты | бюджет Респуб-лики Татарстан | бюджет Респуб-лики Татарстан | бюджет Респуб-лики Татарстан |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| - хезмәттәшлекне алга таба үстерүгә, мәдәни бәйләнешләр урнаштыруга юнәлдерелгән республика чараларында катнашу;<br>- Бөтендөнья татар яшьләре форумы делегатлары өчен бәйрәм чарасы оештыру. | | | | | | | |
| 4.2. «Арча якташлары»якташлары белән традицион очрашуны оештыру | Башкарма комитетның «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 25,0 | район бюджеты 25,0 | район бюджеты 25,0 | район бюджеты 25,0 | район бюджеты 25,0 |
| **5. Татарстан Республикасының Арча муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру** | | | | | | | |
| 5.1. Туган тел көнен (26 апрель) һәм рус теле көнен (6 июнь) бәйрәм итүгә багышланган чаралар циклын оештыру һәм үткәрү | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026 - 2030 еллар | район бюджеты 13,0 | район бюджеты 13,0 | район бюджеты 13,0 | район бюджеты 13,0 | район бюджеты 13,0 |
| 5.2. Шигърият Бәйрәме. Бөек татар халык шагыйре Г.Тукайның туган көненә багышланган чаралар циклын оештыру һәм үткәрү | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, ТРК «Арча», «Арча хәбәрләре» газетасы редакциясе | 2026 - 2030 еллар | район бюджеты 22,0 | район бюджеты 22,0 | район бюджеты 22,0 | район бюджеты 22,0 | район бюджеты 22,0 |
| 5.3. Бөек татар халык шагыйре Г.Тукайга багышланган республика Тукай укуларын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, | 2026 - 2030 еллар | район бюджеты 20,0 | район бюджеты 20,0 | район бюджеты 20,0 | район бюджеты 20,0 | район бюджеты 20,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **6. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-белем бирү һәм мәгълүмати тәэмин итү** | | | | | | | |
| 6.1. “Арча үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре” муниципаль бюджет учреждениесе һәм аның филиаллары фондларын татар, рус, мари һәм башка телләрдә Россия халыклары әсәрләре белән туплау | «Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026 - 2030 еллар | Федераль-ный бюджет | Федераль-ный бюджет | Федераль-ный бюджет | Федераль-ный бюджет | Федераль-ный бюджет |
| **7. Программа куйган бурычларны үтәү кысаларында республика, бөтенроссия, халыкара бәйгеларда һәм фестивальләрдә катнашу** | | | | | | | |
| 7.2. “Уйнагыз гармуннар!” республика халык иҗаты бәйрәмендә катнашу | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе исполнительного комитета, «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 |
| 7.3. “Каравон” Бөтенроссия рус фольклоры фестивалендә катнашу | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе исполнительного комитета, «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 |
| 7.4. Мариларның традицион мәдәнияте “Семык” республика бәйрәмендә катнашу | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе исполнительного комитета, «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 | район бюджеты 3,0 |
| 7.5. “Тере чишмә” халыкара халык сәнгате бәйгесендә катнашу | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, Башкарма комитетның «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Арча балалар сәнгать йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | | | | | | |
| 7.6. “Чулпан” балалар үзешчән иҗаты төбәкара фестиваль-бәйгесендә катнашу | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, Башкарма комитетның «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Арча балалар сәнгать йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 |
| 7.7. “Шома бас” Халыкара бию иҗаты фестиваль-бәйгесендә катнашу | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, Башкарма комитетның «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Арча балалар сәнгать йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 |
| 7.8. “Этномириада” Халыкара традицион сәнгать мәдәнияте фестиваль-бәйгесендә катнашу | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, Башкарма комитетның «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Арча балалар сәнгать йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 |
| 7.9. “Талантлар берлеге” бөтенроссия балалар һәм яшүсмерләр иҗаты фестиваль-бәйгесендә катнашу | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, Башкарма комитетның «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, | 2026 – 2030 еллар | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 | район бюджеты 2,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Арча балалар сәнгать йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | | | | | | |
| 7.10. “Без – Бердәм Россия балалары!” балалар һәм яшүсмерләр иҗатының төбәк бәйге-фестивалендә катнашу | «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, Башкарма комитетның «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Арча балалар сәнгать йорты» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 2026 – 2030 еллар | **район** бюджеты 2,0 | **район** бюджеты 2,0 | **район** бюджеты 2,0 | **район** бюджеты 2,0 | **район** бюджеты 2,0 |